# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгүт авыл җирлегендә,
Мәсгүт торак пунктында
үзара салым кертү турында

**24 ноябрь 2023 ел.** **№ 2**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт торак пунктында 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән карата 500 сум күләмендә, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Урам яктыртуын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтүләргә);
- Азнакай муниципаль районы Мәсгүт торак пунктында зиратны ремонтлау, коймалар урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Зират коймасын эшләү (демонтаж, монтаж, панельләр сатып алу);
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт торак пунктының үзәкләштерелгән чишмәсеннән эчә торган суны анализлау);
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карау өчен (грейдер белән юлларны тигезләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында, Мәсгүт авыл җирлегенең Мәсгүт торак пунктында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Халык җыенында рәислек итүче,
Мәсгүт авыл җирлеге башлыгы:

Д.З. Миңнеханов